**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫН ХӘЛ ИТҮ**

2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында
Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Гулкин авыл җирлегенең Иске Ялан торак пунктында

**24.11.2023** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлегенең Иске Ялан торак пунктында

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Гулкин авыл җирлеге Иске Ялан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем Инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:
- Нагорная урамына вак таш җәюгә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында (Гулкин авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) кабул ителгән көннән..

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Гулкин авыл җирлеге башлыгы ____________ (имза) С.Д.Инькова (имза расшифровкасы)